МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

25.12.2014 № 21-53-64

Казань ш.

**Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыкларына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының норматив-хокукый актларын федераль законнарга туры китерү максатыннан чыгып, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 07.09.2007 ел, № 21-53-83 боерыгы (Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 29.12.2008 ел, № 21-53-85, 15.06.2011 ел, № 21-53-45, 17.02.2012 ел, № 21-53-6, 04.07.2013 № 21-53-34 боерыклары нигезндә кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы бюджетын үтәү буенча операцияләр учеты өчен Татарстан Республикасы бюджеты дефицитын финанслау чыганакларының төп администраторларының (администраторлар), Татарстан Республикасы бюджет средстволарын төп бүлүчеләрнең, бүлүчеләрнең һәм бюджет средстволарын алучыларның лицевой счетларын ачу һәм алып бару тәртибе турында инструкциягә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктта “тере һәм тере булмаган акчалар” дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

9.3.1 – 9.3.14 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

9.4.1 пунктта “тере акчалар белән исәп-хисап нигезендә” дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

13.6 пунктта “һәм тере акча средстволарын алу өчен документлар” дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

№ 14-17 кушымталарны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 17.11.2010 ел, № 21-53-80 боерыгы ( Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 15.06.2011 ел, № 21-53-44, 17.02.2012 ел, № 21-53-5боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы бюджет һәм автоном учреждениеләренең лицевой счетларын ачу һәм алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10.3.1 – 10.3.13 пунктларны үз көчен югалткан дип танырга;

11.6 пунктта “һәм тере акча средстволарын алу өчен документлар” дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

№ 12-15 кушымталарны үз көчен югалткан дип танырга.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 31.12.2010 ел, № 21-53-92 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджет учреждениеләре средстволары хисабына касса түләүләре үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта “(тере акчалар алуга”) дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

10 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;

11 пунктта “тере акчалар алуга”, дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 31.12.2010 № 21-53-93 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы автоном учреждениеләре средстволары хисабына касса түләүләре үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктта “(тере акчалар алуга”) дигән сүзләрне төшереп калдырырга;

9 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

5. Бу Боерык 2015 елның 1 гыйнварыннан килеп чыккан хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

6. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментына бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәтергә.

7. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары - Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры М.Д.Фәйзрахмановка йөкләргә.

**Министр** **Р.Р.Гайзатуллин**